ГЛАВА МАЙДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.48, с. Майдан, 422587

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ МӘЙДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет ур., 48 нче йорт, Мәйдан авылы, 422587

Тел.: (84379) 35-0-48, факс: (84379) 35-0-48.

17.11.2023 № 3

КАРАР
Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Мәйдан авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 17 ноябрендә «Сез 2024 елда Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Мәйдан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?- «Майдан авылының Молодежная, Кооператив, Киров урамнары буенча юлларны ремонтлау өчен, товарны тәэмин итүче хисабына билгеләнгән пунктка кадәр китереп бирү белән вак таш сатып алу», дигән сорау буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены протоколы төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 86 катнашучысы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 53 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенында 52 катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенда 1 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авылы җирлегенең Мәйдан авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2024 елда Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең Мәйдан авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән ташламалы категория гражданнарыннан тыш, Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең Мәйдан авылында 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?– «Мәйдан авылының Молодежная, Кооператив, Киров урамнары

буенча юлларны ремонтлау өчен, товарны тәэмин итүче хисабына билгеләнгән пунктка кадәр китереп бирү белән вак таш сатып алу», дигән сорау буенча карарны таныргa.

3. Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең Мәйдан авылында гражданнар җыены нәтиҗәләрен Мәйдан авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында игълан итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче В.В. Михеев